# Модельләрдә - автомобиль тарихы










**Эшне башкарды:**
**Ханова Флера Гайнутдиновна,**
**ТР Тукай муниципаль районы «Яңа Бүләк төп гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе.**

# «Нами-1»

Россиядә машина төзү тармагын киңәйтергә кирәк була . Моның өчен 1921 елда махсус ”Фәнни автомотор институты“ төзелә (Нами). Аның хезмәткәрләре безнең ил өчен яраклы машина төзү эшенә керешәләр . Шулай итеп , 1927 елда Россиядә “Нами-1” исемле беренче җиңел авто-мобиль барлыкка килә .Ул моңарчы төзелгән машиналардан гадилеге белән аерылып тора . Әмма аны әнә шул артык гадилеге харап итә дә . Суыту системасы һава белән генә эшләгәнгә , “Нами” тиз кыза , моторы бик тавышлы була , өстәвенә , рус инженерлары арткы валга дифференциал дигән механизм куеп мәшәкатьләнәләр. Дифференциал – өстерәүче тәгәрмәчләргә борылышларда төрле тизлекләрдә әйләнергә мөмкинлек бирә . Нәтиҗәдә , шин һәм тәгәрмәч тузмый .



Автомобиль «НАМИ-1»

# Беренче йөк машиналары

**Әлбәттә, автомобиль кеше утырып йөрү өчен генә уйлап табылмаган. Аның белән йөк ташу турында да хыялланганнар. Һәм, ниһаять, 1924 нче елда беренче йөк машиналары АМО-Ф15 (хәзерге ЗИЛ) ясала. Баштарак аларның конструкциясе бик гади була: кузовның арткы өлешен яссы итеп ясап, аңа зур әрҗә генә урнаштыралар. Ләкин биредә кыенлык килеп чыга: авыр йөк төягән машина кечкенә генә пычракта да бата торган була. Шунлыктан, арткы тәгәрмәчләргә бераз үзгәреш кертәләр. Артка икешәр көпчәк куялар. Бүгенге йөк машиналарында да шулай.**



## «Москвич»

**Мәскәү автомобильләр җыю заводы 1930 нчы елда эшли башлый . Башта биредә Американың «Форд -АА» модельләре җыела , ә 1933 нче елда бу завод ГАЗ ның филиалына әйләнә . Утызынчы еллар ахырында ул кабаттан мөстәкыйль предприятиегә әйләнә . Мәскәү кечелитражлы автомобильләр заводы 1947 нче елда «Москвич 400» исемле беренче җиңел машина чыгара башлый. Совет заманында «Москвич-412», «Москвич-2141» модельләре иң киң таралганнардан исәпләнә. Популярлык буенча алар « Жигули »лардан гына калышалар.**



# «ГАЗ»

1932 нче елда Түбән Новгородта йөк автомобильләре заводы ачыла. Шәһәр исеменнән чыгып аны «НАЗ» дип атыйлар . Әмма соңрак ул «ГАЗ» га әйләнә , чөнки Түбән Новгородны Горький дип үзгәртәләр. Аны эшкә кушуда , беренче модельләрне үзләштерүдә АКШ ның «ФОРД» концерны мөһим роль уйный . 1956 нчы елда ул җиңел автомобильләр чыгара башлый . Җиңел автомашиналарны завод конструкторлары үзләре уйлап таба . Аеруча «ГАЗ-20 Победа », «ГАЗ-21 Волга» чыдамлыклары белән танылa .



# «МАЗ 200»

Бөек Ватан сугышы вакытында йөк күтәрүчәнлеге зур булган универсаль йөк машиналарына ихтыяҗ зур була. 1945 елда Ярославль автомобиль заводында «ЯАЗ 200» йөк машинасын ясыйлар. 1952 елдан башлап бу йөк машиналарын Минск автомобиль заводында чыгара башлыйлар. Аны «МАЗ 200» дип йөртәләр.



# « ГАЗ-20М »

Бу автомобиль зур сенсация була. «ГАЗ-20М» дип аталса да, халык телендә ул «Победа» булып йөри. Бик тотырыклы, матур дезайн белән эшләнгән әлеге автомобиль югары комфортабельлеккә ия. Ә моңарчы чыккан автомобильләрдән иң зур аермасы – аның рамы булмый. Бөтен механизмнар чыныктырылган кузовка беркетелә.



# «ГАЗ-21М»

«ГАЗ» заводы да тик ятмый, 1956 елда ул да җиңел автомобильләр чыгара башлый. Авыр «Победа»га алмашка җиңелрәк «ГАЗ-21М» килә. Шулай итеп, «Волга» автомобиленә нигез салына.



# Түрәләр машинасы

**Кызганыч, Россия автомобильләр белән әллә ни мактана алмый. Машина төзелеше безгә зур авырлык белән үтеп керә. Революция белән гражданнар сугышыннан соң илдә җимерек автомобильләр генә кала. Мәскәүдә махсус «Автоимпорт» исемле оешма төзелә. Ул түрәләр өчен «Кадиллак», «Роллс-Ройс», «Мерседес» кебек автомобильләрне чит илләрдән кайтару белән шөгыльләнә. Һәрбер чорда түрәләр өчен махсус машина кирәк булган. «ГАЗ-13» әнә шулар өчен чыгарылган. «Чайка» дип йөртелүче бу автомобильнең тапшырулар тартмасына (коробка передач) зур үзгәреш кертелә. «Чайка»га автомат тапшырулар тартмасы куела.**



# «ГАЗик»

**Рәсемдә – «ГАЗ—67» , авыл җирендә кайчандыр бик популяр булган «ГАЗ—69»ның борынгы бабасы . Бу автомобиль теләсә нинди юлсыз җирдән дә җиңел генә үтә алуы белән данлыклы . Бервакыт автозавод жиһазларының бер өлешен илнең түренәрәк күчерә башлыйлар һәм шулай итеп Ульяновск һәм Миасс (Чиләбе өлкәсе) шәһәрләрендә ике зур завод барлыкка килә , чөнки сугыш башлангач, заводларны илнең эченәрәк эвакуациялиләр.**



# «УАЗ»

**Ульяновск автозаводы 1942 елда Сталин исемендәге заводның эвакуацияләнгән цехлары нигезендә барлыкка килә . Аның тәүге исеме- «УльЗИС». Сугыш ва-кытында Ульяновскида «ЗИС - 5» йөк машиналарын җыялар . Ә сугыш тәмам-лангач бу завод «ГАЗ» белән хезмәттәшлек итә башлый һәм бирeдә «ГАЗ-АА “ полуторкалары чыгарыла. 1954 елда «ГАЗ-69», 1972 елда «УАЗ-469» чыга башлый. Әмма заманча «УАЗ-3160/62» аны кысырыклый башлады. Рәсәй автопаркында «УАЗ »лар берничә процент кына тәшкил итә . Бу исә аларның сәудәгә күптән түгел генә чыгарылуы белән аңлатыла . Чөнки базар шартларына күчкәнче , бу завод армия һәм башка дәүләт структуралары заказларын гына үтәде.**



# «СеАЗ»

Серпухов автозаводы урынында XVII гасыр башында кече яшьтәге җина-ятчеләр колониясе булган . Биредә 1939 елда трофей мотоцикларын ремонтлау буенча завод оештырганнар . Илленче елларда Серпуховта инвалидлар өчен мотоколяскалар җитештерү үзләштерелә . (Л.Гайдайның « Операция Ы » фильмында Ю.Никулин , Е.Моргунов , Г.Вицин шуңа утырып йөри). «Иж-49» мотоциклы двигателе куелган бу мото-машина 1962, 1970 елларда зур үзгәреш кичерә, ә 1987 елдан исә заводта «Ока» автомобиле чыгарыла башлый. Инвалидларга тәгаенләнгән «Ока»лар да әүвәл шушында җыела.



# «Иж»

«Ижмаш – Авто» (Ижевск) акционерлар җәмгыятенең тарихы 1966 елдан баш-лана. Бу чорда ил халкының җиңел машиналарга мохтаҗлыгы арта. Биредәге тәүге «Москвич» машинасы Мәскәүнең Ленин комсомолы исемендәге автоза-воды сызымнары буенча җыела. Ижевск заводының аякка басуында маршал Устиновның ярдәме зур була. Бу завод, башкалардан аермалы буларак, ком-плектлаучы детальләр һәм узеллар җитештерми. Двигательләр – Уфада, тизлек тартмалары – Омскида, подвеска һәм руль колонкалары Пермьда чыгарыла, радиаторлар Воткинскидан алына. Ижевскида уйлап табылган тәүге машина – «Иж-2125». Халыкта ул «Комби» дип йөртелә. Яңа «Иж-2126» моделе дә киң куллану алды.



# «Нива»

1977 елда «ВАЗ» яңа автомобиль чыгара башлый. Әлеге машинаның кузовы шактый югары күтәрелгән, дүрт тәгәрмәче дә өстери, өстәвенә, салоны да комфортабельле. Бу – « Нива» машинасы.




# Иң озын автомобиль

АКШта яшәүче Джей Орберг 30 метр ярымлы автомобиль ясаган! Анда йөзәргә бассейн да, йокларга караваt та бар. Бу машина хәтта борылышларда сыгыла да ала икән!



# Иң озын юл

**Ирвин Гордон 1966 елда чыккан үзенең «Вольво Р-1800» машинасында 3 миллион 200 мең километр юл үткән. Әгәр ул Җир тирәли йөргән булса, аны 80 тапкыр әйләнеп чыккан булыр иде!!!**



# Тиз йөрешле автомобиль

«Макларен F1» автомобиле тизлеген сәгатенә 386,7 километрга чаклы җиткерә алган. Бу – пассажир машиналары өчен рекорд!



# Иң кечкенә автомобиль

«Пил 50» автомобиленә гараж бөтенләй кирәкми. Аны шкафка яшереп куеп та була! Автомобильнең озынлыгы нибары – 134 см, киңлеге – 99 см, ә биеклеге – 134 см гына. Аның авырлыгы бары тик 59 кг гына.

